**Татарстан Республикасы Сарман муниипаль районы Әлмәт авыл җирлеге муниципаль берәмлеге составына керүче Әлмәт авылы халык җыены карары**

**№1** **13.11.2019**

**Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Әлмәт авыл җирлеге составына керүче Әлмәт авылында халык җыены нәтиҗәләре турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьялары нигезендә 2019 елның 13 ноябрендә «I нче группа инвалидлар; ялгыз өлкән кешеләр; вакытлы хәрби хезмәт үтүче гражданнар; көндезге бүлекләрдә укучы студентлардан кала, Әлмәт авыл җирлегендә теркәлгән 18 яше тулган һәр гражданга 2020 елда үзара салымны 200 сум күләмендә кертергә һәм шул акчаларны түбәндәге җирле мәсьәләләрне хәл итәргә тотарга Сез ризамы:

- Әлмәт авылының Ленин урамында урнашкан эчә торган су коеларын чистарту һәм төзекләндерү;
- Әлмәт авылы территориясенә урнаштыру өчен реклама щитлары, стендлар, баннерлар сатып алу;
- Әлмәт авылы Ленин урамына янгын гидранты сатып алу һәм урнаштыру;
- Әлмәт авылы Ленин урамындагы күперне төзекләндерү өчен төзелеш материаллары сатып алу;
- Әлмәт авылында массакүләм чаралар (Сабантуй, өлкәннәр көне, инвалидлар көне, 9 Май, яшьләр арасында волейбол, теннис ярышлары) үткәрү өчен бүләкләр сатып алу;
- Әлмәт авылы Сабан туе территориясен электр белән тәэмин итү өчен кабель сатып алу;
- Әлмәт авылына урам яктырткычлары сатып алу;
- Әлмәт авылы территориясендә үлән чабу һәм куаклар кисү;

ӘЙЕ ЮК?».

мәсьәләсе буенча үткәрелгән гражданнар җыены нәтиҗәләре нигезендә гражданнар җыены беркетмәсе төзелде.

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:

Сайлау хокукына ия булган җыенда катнашучылар исемлегенә 322 катнашучы кертелгән, җыенда катнашучылар саны 272 кеше.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча халык җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

«Әйе» позициясе өчен халык җыенында катнашкан 272 кеше тавыш бирде; «Юк» позициясе өчен җыенда катнашучы 0 кеше тавыш бирде.

Бәян ителгәннәрдән чыгып, халык җыены карар итте:

1. Сарман муниципаль районы Әлмәт авыл җирлеге составына керүче Әлмәт авылында узган халык җыенын-уздырылган, нәтиҗәләрен- дөрес дип танырга
2. Сарман муниципаль районы Әлмәт авыл җирлеге составына керүче Әлмәт авылында түбәндәге сорау буенча узган гражданнар жыены карарын кабул ителгән дип танырга: «I нче группа инвалидлар; ялгыз өлкән кешеләр; вакытлы хәрби хезмәт үтүче гражданнар; көндезге бүлекләрдә укучы студентлардан кала, Әлмәт авыл җирлегендә теркәлгән 18 яше тулган һәр гражданга 2020 елда үзара салымны 200 сум күләмендә кертергә һәм шул акчаларны түбәндәге җирле мәсьәләләрне хәл итәргә тотарга Сез ризамы:
- Әлмәт авылының Ленин урамында урнашкан эчә торган су коеларын чистарту һәм төзекләндерү;
- Әлмәт авылы территориясенә урнаштыру өчен реклама щитлары, стендлар, баннерлар сатып алу;
- Әлмәт авылы Ленин урамына янгын гидранты сатып алу һәм урнаштыру;
- Әлмәт авылы Ленин урамындагы күперне төзекләндерү өчен төзелеш материаллары сатып алу;
- Әлмәт авылында массакүләм чаралар (Сабантуй, өлкәннәр көне, инвалидлар көне, 9 Май, яшьләр арасында волейбол, теннис ярышлары) үткәрү өчен бүләкләр сатып алу;
- Әлмәт авылы Сабан туе территориясен электр белән тәэмин итү өчен кабель сатып алу;
- Әлмәт авылына урам яктырткычлары сатып алу;
- Әлмәт авылы территориясендә үлән чабу һәм куаклар кисү;

3. Гражданнар җыены нәтиҗәләрен http://pravo.tatarstan.ru веб-адресы буенча «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында», Сарман муниципаль районының Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында һәм Әлмәт авыл җирлегенең махсус мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән игълан итәргә.
4. Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Әлмәт авыл җирлегенең әлеге карарын Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары Регистрына кертү өчен җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Әлмәт авыл җирлеге башлыгы: Д. Ә. Газизов